ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 466-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары С.М. Захарова, С.А. Вострикова, Е.И. Кузьмичева, А.Г. Фомичёв, Р.Р. Хәсәнов, А.Ә. Яһудин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 466-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2144-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
С.М. Захарова,
С.А. Вострикова,
Е.И. Кузьмичева,
А.Г. Фомичёв,
Р.Р. Хәсәнов,
А.Ә. Яһудин
тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяның 1 өлешенә «игълан ителүенә бәйле рәвештә» сүзләреннән соң «, шулай ук ирнең яисә хатынның граждан хәле акты язмасына үз җенесен үзгәртүе турындагы үзгәреш кертүгә бәйле рәвештә» сүзләрен өстәргә;

2) 79 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Мондый ярдәмнән баш тарткан һәм алимент түләү турында ир белән хатын арасында килешү булмаган очракта, моның өчен матди мөмкинлеге булган ирдән яисә хатыннан суд тәртибендә алимент түләүне таләп итү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) хезмәткә сәләтсез ярдәмгә мохтаҗ ир йә хатын;

2) йөклелек чорында ир хатыны;

3) уртак бала туган көннән алып өч ел дәвамында фактта аны карап торучы ир йә хатын;

4) уртак инвалид баланы аңа унсигез яше тулганчы фактта карап торучы яисә балачактан I группа уртак инвалид баланы фактта карап торучы ярдәмгә мохтаҗ ир йә хатын.»;

3) 80 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Матди мөмкинлеге булган элеккеге ирдән йә хатыннан суд тәртибендә алимент түләүне таләп итү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) никахта торганда барлыкка килгән йөклелек чорында элеккеге ир хатыны;

2) уртак бала туган көннән алып өч ел дәвамында фактта аны карап торучы элеккеге ир йә хатын;

3) уртак инвалид баланы аңа унсигез яше тулганчы фактта карап торучы яисә балачактан I группа уртак инвалид баланы фактта карап торучы ярдәмгә мохтаҗ ир йә хатын;

4) никах өзелгәнче яисә никах өзелү вакытыннан бер ел дәвамында хезмәткә сәләтсез булып калган ярдәмгә мохтаҗ элеккеге ир йә хатын;

5) әгәр ир белән хатын озак вакыт никахта торып, никахлары өзелгәннән соң биш елдан соңрак булмаган вакыт эчендә пенсия яшенә җиткән ярдәмгә мохтаҗ элеккеге ир йә хатын.»;

4) 116 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14) җенесен үзгәрткән затлар.»;

5) 134 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) җенесен үзгәрткән затлар.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

**«Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**аңлатма**

Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы Гаилә кодексының аерым нигезләмәләрен федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 июлендәге 386-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 13 статьясындагы 1 өлешенә ирнең яисә хатынның граждан хәле акты язмасына үз җенесен үзгәртүе турындагы үзгәреш кертү никахны өзү өчен нигез булуны күздә тота торган нигезләмә өстәү, шулай ук Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 статьясындагы 1 өлешенә һәм 134 статьясындагы 1 өлешенә үз җенесен үзгәрткән затларга балаларының опекуннары (попечительләре) һәм аларны уллыкка (кызлыкка) алучылары булуны тыюны билгеләүче үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

«Россия Федерациясе Гаилә кодексының 89 һәм 90 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 31 июлендәге 403-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 79 статьясындагы 2 өлешенә һәм 80 статьясындагы 1 өлешенә уртак бала туган көннән алып өч ел дәвамында аны карап торучы ир белән хатынга, шулай ук элеккеге ир белән хатынга алимент түләү өлешендә үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә. Закон чыгаручы тарафыннан ир белән хатынның уртак баласы туган көннән алып аңа өч яшь тулганчы аны баланың атасы фактта карап тору очраклары да исәпкә алынган. Бу вакытта баланың анасы аны тәрбияләүдән һәм карап тотудан читләшкән була.

**«Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.